Чыганак: Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби нәфис, документаль, биографик җыентык / авт.-төз. Җ. Миңнуллин (фәнни мөх.); редкол.: И. Г. Әхмәтҗанов, Р. И. Вәлиев, Ф. М. Рәфыйков. – Казань: Җыен, 2012. – 479 б.: фоторәс. б-н. – (Шәхесләребез). – Библиогр.: б.465-474.

## *Шакир Шамильский*[1]

### Беренче татар артисткасы

Татар сәнгатенең атаклы бу артисткасы белән мин 1910 елда Пермь шәһәрендә очраштым. Ул «Сәйяр» труппасы белән гастрольгә килгән иде. Бу труппа «Яшь хатын» (Таҗдаров) һәм «Хуҗа һәм приказчик» (Богданов) пьесаларын куйды. «Хуҗа һәм приказчик» спектаклендә асрау ролендә миңа да уйнарга туры килде, шунлыктан мин аларның берничә репетицияләренә йөргәләдем. Бу вакытларда яшүсмер булган минем үземнең дә театр белән кызыксынып, артист булырга дәртләнеп йөргән чакларым иде.

Репетиция вакытларында Сәхибҗамал ханымның труппада гади артистка гына булмавын, ә бәлки аерым зур урын тоткан кеше икәнен сизергә була, ул репетицияләрне үзе алып бара, артистларны өйрәтә һәм үзенең уены белән үрнәкләр күрсәтә иде. Кыскасы, труппада режиссёрлык эшен дә ул алып барганга, труппа членнары аның күрсәтүләре белән нык хисаплашалар һәм аңа зур хөрмәт күрсәтәләр иде.

Спектакльләрдән соң да Пермь җәмәгатьчелеге Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжскаяның уены турында озак вакытларга хәтле мактап, сагынып сөйләде. Пермь тамашачыларының күңелләрендә аның уены онытылмаслык булып калды.

[1] *Шамильский (Вахитов) Шакир Гани улы* (1892–1945), актёр, режиссёр. ТАССР ның атказанган артисты (1945).



Ул вакытларда Сәхибҗамал ханымның табигый таланты, эчке һәм тышкы актёрлык техникасының бай булуы, зур һәм тирән рольләр сораганлыгын күрсәтеп тора иде. Ул чордагы рус матбугаты да Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжскаяның уенына бәһа биргәндә аны «ялтырап торган талант» дип атады.

Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская белән икенче һәм озак вакытка очравым 1912 елның маенда, Уфада булды. Пермьдә «Сәйяр» килеп киткәч, минем язмышым бөтенләйгә хәл ителде. Мин, һичнәрсәгә карамастан, артист булырга карар бирдем. 1911 елны Пермьгә концерт белән җырчы Фәттах Латыйпов килде. Ул миңа һәм минем иптәшләрем Хәнҗәров белән Юсуповка: «Мин моннан Казанга барам һәм анда бер-ике артистка белән сөйләшеп, Уфада икенче труппа төзәргә уйлыйм. Мин инде ул хакта Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская белән дә сөйләшкән идем. Ул «Сәйяр»дан китеп, Уфага килергә риза һәм аның белән артистка Фәхрениса Сәмитова да киләчәк. Әйдәгез, Уфада труппа төзик», – дип сөйләде. Без шатланып риза булдык.

Бу эш 1911 елның ахырында – 1912 елның башларында булды. Ф.Латыйпов Казанга китте, ә без аңардан хәбәр көтеп калдык. 1912 елның май башында Уфадан, Ф.Латыйповтан безне Уфага чакырып телеграмма килде. Телеграммада: «Артистка Гыйззәтуллина-Волжская һәм Сәмитова Уфага килделәр, сез дә тизрәк килеп җитегез», – диелгән иде. Телеграмманы алгач та мин юлга чыктым. Ике иптәшем бер атнадан соң килделәр. Шулай итеп, Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская кул астында икенче татар труппасына нигез салынды. Бу труппада Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская

1918 елга хәтле юлбашчылык һәм режиссёрлык эшен алып барды. Сәхибҗамал ханым бу труппаның йөрәге һәм җаны иде. Бу эштә үзенең зур организаторлык көче барлыгын да нык итеп күрсәтә алды. Аның чыдам һәм нык характеры, нинди генә авырлыкка да исе китмәве безне, ирләрне дә, гаҗәпкә калдыра иде. Хәзер уйласаң, ис китә. Бу кадәр чыдамлык, үз эшеңә шулкадәр бирелү, аны чиксез сөю, болар чыннан да гаҗәпләнмәслек хәл түгел.

Бу труппа «Нур» дип аталды. Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская бу труппа белән Уфа, Оренбург, Урта Азия, Сибирь һәм Урал шәһәрләрен йөреп чыкты. Труппа нинди авыр хәлләргә калганда да, (ә андый хәлләр атлаган саен очрый торган иде) Сәхибҗамал ханым актык киемен сатып, йә ломбардка заклад салып булса да труппаны читен хәлдән чыгарга юл таба, аны таркалудан саклауга бөтен көчен куя торган иде. Ләкин монда Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжсканың иң әһәмиятле булган һәм гомумән татар театрының һәм татар артистларының үсүенә зур ярдәме тигән бер ягына тукталмый китү һич ярамый. Ул да булса аның чын мәгънәсе белән реалистик пландагы бөек бер артистка икәне. Киләчәктә, аның иҗатын нык-лап өйрәнгәндә, бу моментларга тиешенчә тукталырга кирәк булыр, әлбәттә. Монда тик шуны гына әйтәсе килә: Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская татар артистларына, бигрәк тә ул чакларда һәм теоретик, һәм практик яктан әзерлексез, тәҗрибәләре аз булган татар артист һәм артистка-ларына үзенең реалистик уйнау юлларын нык сеңдергән, нык урнаштырган һәм татар сәхнә сәнгатенә билгеле мәктәп – реализм мәктәбе нигезләрен салучыларның берсе һәм иң алдынгысы иде.

Практикада ул моны болай үткәрә иде. Мәсәлән, репетиция вакытларында без уйный торган рольләрне үзе уйнап күрсәтә. Аның фантазиягә бай булуы аңа без күрми калган моментларны да чагылдырырга мөмкинлек бирә, уенына җанлылык, театральность кертә иде. Шулар белән бергә, ул һәрвакыт үзе күргән зур рус артистларының уенын һәм спектакльләрен безгә сөйли иде. Тормышны белүе, хыялга байлыгы, тиз тәэсирләнә алучанлыгы, зур темперамент иясе булуы аркасында Сәхибҗамал ханым тудырган образлар тамашачыда онытылмаслык тирән тәэсирләр калдыра иде. Үзенең уены белән ул безне дә дәртләндерә, күңелләребезне күтәрә иде. Ул безгә һәрвакыт: «Яхшы, шәп артист булырга тырышырга кирәк», – дип әйтә торган иде.

Монда аның якын иптәшләреннән мәрхүм артист Гыйлаҗ Казанскийны да искә аласы килә. Аның яхшы артист булып үсүенә Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжскаяның зур ярдәме тиде. Шулай ук Гыйлаҗ Казанскийның режиссёрлык тәҗрибәсендә дә турыдан-туры аның тәэсире булды.

Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская тарафыннан тудырылган образлардан Таждаровның «Яшь хатын»дагы ролен, Г. Камалның «Бәхетсез егет»ендә Гайни ролен, Ф. Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт»ендә Луиза, А.Н.Островскийның «Гроза»сында Катерина, «Кызганыч бала»да Шәфика, Г. Камалның «Уйнаш»ында Сәрви, «Банкрот»ында Гөлҗиһан һәм башкалар әле хәзер дә күз алдында китми басып торалар. Мәсәлән, аның «Уйнаш»тагы Сәрвиҗамалның финалда ире Әхмәтҗанга тилмереп караулары йөрәкне әрнетеп, бу бичара хатынның тәкъдире өчен күздән яшь агызырга һәм дулкынланырга мәҗбүр итәләр иде. Һәм шуңа капма-каршы булган һавалы, тәкәббер, әче телле Гайнинең яки басынкы, мөлаем, гүзәл табигать баласы, бөтен барлыгы белән сөя белүче Луиза һәм башкалар – болар барысы да Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская иҗатында зур осталык һәм талантлы-

лык художество ягыннан зур югарылыкка күтәрелгән образлар.

*(Истәлек беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналында (1941, №1/2. – Б. 85–98) дөнья күргән. Текст шуннан алынды.)*

***Локман Аитов[1]***

## Артистның тормыш юлы

### Мәкәрҗәдә

Мәкәрҗә!.. Кемнәр генә бирегә килергә ашкынмый! Байлар, хуҗалар бирегә комсыз нәфесләрен басарга, типтерергә, акча түгәргә, күңел ачарга килсәләр, безнең ише приказчиклар, шәкертләр исә берәр эш эзләп, бәхет өмет итеп, байларның типкеләрен алырга, маңгай тирләре түгәргә килә.

Дөрес, мондый шәкертләрнең үткенрәкләре, кесәләрендә беркадәр маялары булганнары, татарча газета-журнал һәм китаплар белән сату итә. Кайберләре кибетләр арасында вакытлы эшкә яллана. Шулай итеп, болар Мәкәрҗәдән бераз өс-башларын юнәтеп, кышын мәдрәсәдә укыганда ачка үлмәслек запас әзерләп тә кайталар. Эш эзләп йөрүчеләрнең исәбе дә, хисабы да юк.

Ярминкә уртасында «Самокат» дип атала торган зур мәйдан: анда карусельләр әйләнә, «туманный» картина күрсәтелә. Атаклы Никитин циркы да шунда. Мәйдан артыннан ук «Хәсрәт бакчасы» китә. Биредә, чыннан да, бик моңсу, бик күңелсез. Көндезләрендә бирегә бай хуҗалар кереп чыккалый.

[1] Аитов Локман Мөхәммәдхан улы (1891–1971), артист, «Нур», «Ширкәт» һәм башка труппаларда эшли. Соңрак Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә иҗат итә.



Алар төрле эшләргә яллыйлар. Байлар тезелеп утырган ярлыларга күз йөртеп кенә үтәләр. Берәрсенең тазалыгы яки кыяфәте ошаса, янына килеп баштанаяк карап чыгалар да, нинди эш барлыгын белдергәч, номерына килергә кушалар.

Мин, гадәтемчә, вывескалар, афишалар, игъланнар укып йөрим. Чү, бу ни бу! Татарча афиша!

«...Мәшһүр артистка Гыйззәтуллина-Волжскаяның катнашы белән «Сәйяр» труппасы тарафыннан спектакль бирелә. Сәхнәгә куеладыр: «Хуҗа һәм приказчик».

Афишаны кабат-кабат укып чыктым. Урын эзләү кайгысы онытылды. Минем теләк татар артистларын күрү иде. «Барыйм әле, берәрсен күреп булмасмы», – дип, «Самокат»тагы шул театрны эзләп киттем.

Барып кереп, швейцардан: «Биредә татар артистларыннан кем дә булса бармы?» – дип сорадым. Ул: «Әнә алар, репетиция ясап яталар», – дип әйтеп тә бетермәде, бүлмәдән башына котелок эшләпә, өстенә суртюк кигән озын буйлы бер кеше килеп чыкты. Мин аның артист булуына шикләнмичә башымны идем. Ул минем каршыма килде дә:

– Нихәл, чибәр егет? Кемне эзлисең? – дип сорады.

Шундый мәһабәт кешенең ачык күңеллелегенә мин гаҗәпләндем. Үземнең Пермь шәһәреннән килүемне, театр сөюче булуымны әйттем. Ул: «Әйдә алайса, таныш булыйк. Мин артист Нури Сакаев булам!», – дип кулын сузды. Шуннан соң ул Пермь хәлләрен сораштырды да: «Без дә шул якларга барып чыгарга исәп тота идек... Әйдә әле, мин сине Кариев белән таныштырыйм», – дип, култыклап алып кереп тә китте.

Бер диванда Кариев, Мортазин, Волжская нәрсәдер сөйләшеп утыралар иде. Мин аларның һәркайсы белән кыяр-кыймас кына танышып чыктым. Кариев Пермь шәһәре, гомумән Урал яклары